Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№2
Октябрь 2022 г.

## 5 октября– Всемирный день учителя!



## *С Днем Учителя!*

Уважаемые педагоги, поздравляем Вас с Всемирным Днём учителя! От всего сердца желаем вам здоровья, успехов, оптимизма и новых творческих свершений в вашем благородном труде. Благодарим вас за доброту, душевное участие и самоотверженность, ввиду которых определяются высокие результаты образовательной деятельности. Пусть из года в год судьба дарит Вам встречу с признательными, стремящимися к знаниям учениками. Пусть новостная лента сообщает о выдающихся достижениях ваших выпускников, порождая чувство гордости и выставляя отличную оценку вашим профессиональным навыкам.

### В этом выпуске:


- Из школьной жизни
- Учителя для нас, вы-свет в окошке
- Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле укытучыларыбыз!
- Укытучыма мәдхия
- Слово об Учителе
- Беренче укытучым

# *Из школьной жизни*

1 октября – Международный день пожилых. В этот день наша школа активно принимала участие в поздравлении пожилых людей.

Ученики 9В класса приняли участие в патриотической акции «Ветеран живет рядом», цель которой поддерживать связь между поколений, оказывать помощь ветеранам, развивать чувство патриотизма у детей.





В честь дня пожилых людей, мы поздравили бывших работников образования своей школы. Вручили подарки от "Вамин Татарстан", а также открытки, которые сделали учащиеся нашей школы.

## *Космическое прошлое...*

Навсегда останется в памяти человечества первый спутник, первый в истории полёт человека в космическое пространство. Человечество превратило мечту в реальность.

2 этап Марафона Зихангиров, посвящённый Космосу. Музаффарова Ильзира подготовила материал на тему: «Искусственные спутники Земли». Учащиеся узнали, что существуют естественные и искусственные спутники. Получили информацию о первом искусственном спутнике Земли - Спутник-1.

Ахметова Камиля рассказала о Луне, самом известном искусственном спутнике. Ситдикова Диана рассказала о человеке, который внёс большой вклад в развитие космоса- Циолковский К.Э. Каждый желающий смог принять участие в увлекательной, познавательной беседе.

12 апреля 1961 года Юрий Гагарин стал первым человеком в мировой истории, совершившим полёт в космическое пространство. Ракета-носитель «Восток» с кораблём «Восток-1», на борту которого находился Гагарин, была запущена с космодрома Байконур, в 9 ч 07 мин по московскому времени.






3 октября у нас в гостях были Адгамова Юлия Ильдаровна, а также заместитель главы администрации Арского района Мухаметова Алсу Фирдаусовна.

Юлия Ильдаровна провела тематический урок “Беспилотные технологии” в рамках года цифровизации и республиканской программы “Урок цифры”.

Целью общеобразовательной программы по тематическому направлению «Беспилотные технологии» является формирование знаний, обучающихся в области применения беспилотных аппаратов.



# Учителя для нас, вы-свет в окошке

**5 октября** – Всемирный день учителя. В этот прекрасный день наши учителя вновь почувствовали себя учениками. Для них были подготовлены уроки в 12 классе. А в завершении этого чудесного дня был подготовлен праздничный концерт.




6 октября состоялась торжественная церемония награждения педагогических работников учреждений образования Арского муниципального района с участием Депутата Государственной думы РФ И.И. Гильмудиновым, начальника отдела дополнительного профессионального образования Р.И.Шаяхметовой, Главой Арского муниципального района И.Г.Нуриевым и начальника управления образования Р.Д.Мухамадияровым. Наша школа заняла 1 место в конкурсе "Цветочные композиция" в номинации "Подвиг моего героя". Награды получили Хасанов Ильнар Ильсурович, Малафеевска Алла Вячеславовна, Халиуллина Оксана Анатольевна.

Поздравляем!






12 октября SMS- дети отряда "Risk" АСОШ 2 приняли участие в проведении антиалкогольной акции "Здоровая пробежка". Цель данной акции- актуализация активной гражданской антинаркотической позиции участников Республиканского антинаркотического проекта "Самостоятельные дети". В рамках акции участники определили место проведения в многолюдном месте, установили плакаты с символикой проекта и плакаты, пропагандирующие ЗОЖ. Среди участников проекта и прохожих, пожелавших принять участие, провели пробежку по определенному маршруту. С прохожими, принявшими участие в акции, подписали однодневный контракт отказаться от вредных привычек. Результатом проведённой акции 7 подписанных однодневных контрактов.



13 октября учащиеся 9а класса посетили библиотеку на мероприятие про профессии сельского хозяйства.

На мероприятии они узнали много интересного об этих профессиях, побеседовали с человеком из управления сельского хозяйства, задавали интересующие вопросы.



13 октября Учащиеся 11 класса приняли участие в мероприятии "Библиотека - твоя территория" в центральной библиотеке. Они интересно прорекламировали художественные произведения Ф. М. Достоевского "Преступление и наказание" и М. Горького "Старуха Изергиль".

# *Рәхмәт Сезгә, хөрмәтле укытучыларыбыз!*

*Килгән чакта башка авырлык,*
*Җитми калса көч я сабырлык,*
*Сиздермичә ярдәм иткәнсез –*
*Сез иң күркәм кеше икәнсез!..*

Кем генә булып эшләсәң дә, һөнәргә өйрәтүчеләре - бер үк кешеләр.

Бала җиде яшь тулгач, мәктәпкә килә. Шушыннан башлана һөнәр ияләренең тамыры. Ә шушы яшь, ныгымаган тамырларга су сибүче кешеләр – укытучылар. Алар бу тамырларны ныгыта һәм зур агач булып үсәргә булыша.

Укытучы... Минемчә, ул иң изге һөнәрләрнең берседер. Ул бит һәр укучыга белем бирүче һәм дөрес юл күрсәтүче. Бу бит күпме көч, сабырлык сорый. Шуңа күрә дә, безгә алар - әнидәй якын кешеләр.

Мин аңлыйм, хәзер укытучыларга бик җиңел түгелдер, чөнки без, укучылар төрле. Шулай булса да, алар безгә белем бирергә тырышалар, тормышны яратырга өйрәтәләр. Ничек кенә булмасын, без аларның сыйныф бүлмәсенә матур киенеп, елмаеп килеп керүләрен көтәбез.

Һәр кешенең яраткан укытучысы буладыр. Минем яраткан укытучым – Булат Шакиров. Ул безне физкультура дәресеннән укыта. Дәрескә кереп тезелгәч, мин аның каршыга атлап килеп, команда бирүен үк ошатам. Дәресләрен бик күңелле үткәрә ул. Булат Фәнил улы безне аңларга тырыша, безнең белән уртак тел таба, төрле сорауларыбызга җавап таба белә. Безне чын егет итеп үстерергә тели. Укытучыбыз үзенең сүзе белән генә түгел, ә тышкы кыяфәте белән дә үзенә тартып тора. Шуның өстенә ул - гадел, түземле, тыныч һәм ягымлы кеше. Аның дәресләрендә без йөгереп, сикереп кенә калмыйбыз, төрле авыр хәллардән котылу юлларын да өйрәнәбез. Ул безне тормышка әзерли, илебезне сакларга кирәклеген аңлата, патриотизм хисләре тәрбияли. Минемчә, хезергесе вакытта бу бигрәк тә кирәктер...

Безнең мәктәбебездә яхшы укытучылар тагын бар. Унбиш ел элек шушы мәктәптә Булат Шакировның сыйныф җитәкчесе булган татар теле һәм әдәбиятыннан белем бирүче, туган телебезнең кадерен белергә төшендерүче укытучыбыз Рәсимә Ибраева, класс җитәкчебез Ильдус Аскаров... Санап китсәң бик күп... Алар һәммәсе дә безнең киләчәгебезне кайгырталар, уңышларыбызга сөенәләр. Һәрберебезнең хәленә керәләр, булышалар. Яхшылыкны онытмаска, башкарган эшләребезнең шатлыгын тоярга да өйрәтәләр.

Без нәрсә генә эшләсәк тә, укытучыларыбызга бурычлы. Әйе, без кайвакыт шук та, тыңламыйбыз да, ләкин без Сезне барыбер ихтирам итәбез! Хөрмәтле Укытучым, синең данлы исемеңне зурлап, хөрмәт белән баш иям...

*Ислам Мингазов,*
*9Б сыйныф укучысы*



## Укытучыма мәдхия

Ул өйрәтте каләм тотарга һәм
Тәүге сызыкларны сызарга.
Ул өйрәтте хәрефләрне теркәп,
Иҗекләрдән сүзләр язарга.

Һәрбер кешенең беренче укытучысы истә кала.

Минем, 2013 нче елның беренче сентяберендә беренче класска тәүге аяк атлавым бүгенгедәй исемдә. Укытучының матур итем елмаеп каршы алуы хәтеремдә.

Резеда Вәлиеваның шигырь юллары минем беренче укытучым Клара Рәхим кызына туры килә. Ул - кулга каләм тотып язарга, хәреф танырга өйрәтүче тәҗрибәле, талчан укытучыбыз. Дәресләрне аңлаешлы һәм бик күңелле үткәрә. Аның белән бергә без мәктәп тормышында, һәрбер эштә бик актив катнаштык. Укытучыбыз безне бик күп нәрсәгә өйрәтте.

Бөртектән көшел җыела. Көшел - ындырда сугылган ашлык өеме. Ашлык бөртеге иртә язда сукаланган кара җиргә төшкән мәлдән, ындыр табагында көшелгә өелгәнче күпме вакыт, күпме хезмәт, күпме ачы тир түгелә. Минемчә, укытучы хезмәтен дә шул ашлык бөртегеннән җыйналган көшелгә тиңләп буладыр. Укытучы кулында бөртекләргә тиң бала язмышы, аларның эчке дөньясы, хискичерешләре, күңел халәте, гамьле карашы, яшәү яме, тормыш мәгънәсе. Алтынга тиң бөртекләрдән җыелган көшел бәрәкәтле булса гына, укытучы бәхетле буладыр...

Укучылар никадәр үрләсәләр, укытучы да шулхәтле югары күтәрелә. Беренче космонавт Юрий Гагаринны да укытучы хәреф танырга өйрәткән. Аннары Гагарин белән бергә, аның күңел түрендә, укытучы да Галәмгә, йолдызлар дөньясына күтәрелгән.

Никадәр сабырлык, балаларга карата олы мәхәббәт таләп итә бу һөнәр. Аның әйткән һәр сүзендә күпме яшерен мәгънә, күпме гамъ, аларның һәркайсы тәрбияви асылга ия. Мөгаллимнең туры сүзенә, йөгерек теленә, зәвыклы сөйләменә сокланмый мөмкин түгел. Аның таләпчәнлеге дә, белемле булсыннар, дип тырышудан килә.

Һәр баланың киләчәгенә юл ачучы кеше дә – укытучы! Киләчәктә нинди зур уңышларга ирешсәк тә, уңышларыбызның башында укытучы торганын онтымыйк!

***Зөһрә*** *Мусина,*
*10 нчы сыйныф укучысы*

## Слово об Учителе

Учителя бывают разные: некоторые из них строгие, кто-то очень добрый…Но для меня самые важные – любящие своих учеников. Именно такой является моя любимая учительница – Сумбуля Жандарова.

Она преподавала татарский язык. Предмет Сумбуля Равильевна объясняла очень интересно, но не за это я её люблю. Меня совершенно пленили её тёплые глаза, мягкость и доброе отношение ко мне. Даже когда я хулиганил, она никогда не злилась на меня. Я чувствовал себя любимым. Возможно, Сумбуля Равильевна была слишком добра ко мне, ведь иногда я несправедливо поступал по отношению к однокласснику, а она не стыдила меня, но это не сделало меня плохим, жестоким человеком. Главный её секрет – любовь к ученикам. Мне кажется, когда тебя любят, ты чувствуешь себя хорошим, достойным, ты получаешь главные лекарства от всех недуг: принятие и нежность. Даже похвала не дарит тебе столько удовольствия, сколько дарит искренний, ласковый взгляд в твою сторону.

В моей жизни было много учителей: некоторые из них были строгими, и я хорошо запомнил их предмет и боялся их, некоторые были нейтральными и забывались, в память же врезались те, кто очень по-доброму ко мне относился. Видимо, каждый из нас больше всего в этой жизни нуждается в любви.

Я никогда не забуду Сумбулю Равильевну, никогда не забуду её опрятный вид, её необычную походку ,как у доброй мамы- медведицы, её лучистый взгляд и доброту. Мне стыдно, что я не навещаю её. Сумбуля Равильевна была особенной, ведь даже родителям иногда не удаётся так принимать детей, как это делают талантливые учителя. И в честь Дня учителя хотелось бы поздравить всех учителей.

Желаем вам, дорогие учителя, успехов в вашем благородном деле, умных, пытливых и смышленых учеников. Пусть ваш труд приносит как можно больше радости и удовлетворения и будет по достоинству оценен. Здоровья вам, счастья, благополучия в семье, нескончаемой энергии и оптимизма. С праздником!

***Ранис*** *Исмагилов,*
*ученик 9 б класса*

## *Беренче укытучым*



Беренче сыйныфка кергәндә, мине кыерсытырлар дип курыкканым, әле дә исемдә. Зифа буйлы, яп-яшь мөләем апа безне класска алып кереп, үзе белән таныштыргач, бераз тынычландым. Ул безне 5 нче сыйныфка кадәр укытачагын әйтте. Аның белән безнең танышу шулай булды. Беренче укытучым - Сабирҗанова Айгөл Тәлгать кызы – бүген дә минем янәшәмдә кебек. Аның киңәшләрен 9 нчы сыйныфка җитсәм дә исемдә тотам, чөнки дүрт ел буе ул безне нәрсәгә генә өйрәтмәде: укырга, язарга, санарга. Аның белән без әйләнә-тирә дөньяны танырга, табигатьне сакларга өйрәндек. Укытучым минем ясаган рәсемнәрне класс алдында мактый да мин тагын да тырышыбрак ясый башлый идем. Хезмәт дәресендә без энә-җеп тотарга, төймә тагарга, хәтта чигәргә өйрәндек. Хәзер инде мин үзем төймә тага, тегә алам. Болар барысы да укытучыбыз ярдәмендә. Ул бик кайгыртучан, хәтта кемнеңдер йөзе моңсу булса да, һичшиксез, килеп, сәламәтлекне сорый, тынычландыра, проблемаларны чишәргә ярдәм итә, кирәксә, табибка җибәрә. Булдыра алмаганны белсә, кабат аңлатыр өчен, дәрестән соң калырга беркайчан да баш тартмый. Әгәр берәребезнең гаиләсендә уңайсызлыклар булса, ярдәм итү өчен әти-әни белән сөйләшә, булыша. Ул миңа кызыклы китап сайларга да ярдәм итә иде. Айгөл Тәлгать кызы гел шат күңелле һәм көләч, ул һәрвакыт ягымлы, аны һаман яхшы билгеләр белән сөендерәсе килә. Аның белән бергә без туган көннәр уздырып, бик күңелле яши идек. Гадәттә дәресләрдән соң сыйныфта тәм-томнар белән чәй эчү оештырыла. Ә моның алдыннан без сәхнәләштереп котлаулар әзерлибез, шигырьләр һәм җырлар өйрәнә идек.

Укытучыбыз безнең белән мәктәптә генә вакыт уздырмады. Без бөтен сыйныф белән паркка йөри, яфраклар җыя идек. Берничә тапкыр театрларга бардык, музейларда булдык. Җәен барыбыз бергә табигатьтә ял итәргә ярата идек. Күңелле уеннар уйнап, саф һава сулап һәм тәм-томнар ашап йөргән чаклар әле дә сагындыра.

Укытучым бик игелекле, ихлас күңелле, ул безне дә дус булырга, бер-беребезне хөрмәт итәргә, ярдәмчел булырга өйрәтте.

Һәр укытучы да үз укучыларына йөрәк җылысын бирергә тырышы, минемчә. Үземнең беренче укытучыма һәм барлык мөгаллимнәргә сәламәтлек, күтәренке рух, укучылар мәхәббәте һәм сабырлык телим. Хезмәтегез өчен рәхмәт Сезгә!

**Карина** Җамалиева
9 Б сыйныфы укучысы

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Алсу Мингазова
***Фотокорреспондент*** Дина Хайрутдинова
***Корректор*** Ранил Заляев
***Редколлегия*** Ислам Гадрахманов
Камиль Гарифуллин

***Адрес:*** ул. Мосовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2